# *Корбанов Харис Мөхәммәт улы*



*Мин, Корбанов Харис Мөхәммәт улы, 1931 нче елның 13 нче июлендә туганмын. Сугыш башланганын урамдагы кешеләрдән ишеттем. Сугышка әтиемне 1941 нче елның җәй аенда озаттык. Ул елны бик күп эшләдек, печән чаптык. Миңа бары тик 10 гына яшь иде әле ул вакытта. Авырлыкларны онытыр өчен урамда уйнап керә идек. Безгә әнибезнең терәге зур булды. Сугышта әтиебез һәлак булды, без бу хәбәрне бик авыр кабул иттек.*

*Сугыш башлану белән тормышлар авырайды, ашарга юньләп юк, чөнки барлык булган әйберләрне сугышка җибәрә идек. Бала чакта күкәрин ашап үстек. Күңелле чаклар бик аз була иде, җәйгә чыккач гел эштә булдык. Мәктәптә дә бары 4 кенә ел укый алдым, башкача мөмкинлек булмады. Мәскәүдән авылга кешеләр кайтарылды. Без аларга бакчаларын казырга булыша, бәрәңгеләр бирә идек. Баштарак әтидән хатлар килде. Исәнлегенә куанып укый идек. Яралылар янына госпитальгә барганым булмады. Кораллар ясау өчен акча белән дә ярдәм итә алмадык, чөнки үзебезгә дә акча юк иде.*

*Сугыш бетү, җиңү турында печән чабып кайтып килгәндә әйттеләр. Бар халык куанды, тик минә әтием генә кайтып җитә алмады...*

*Хәзерге яшь буынга мин сау-сәламәт булсыннар, начар эшләр эшләмәсеннәр һәм әти-әниләренең сүзләрен тыңласыннар дип теләп калам.*